**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГОСЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2022 елның 21 нче ноябре** **№ 61**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Законы » карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 29 маендагы 77 нче номерлы карары белән расланган (2020 елның 18 нче декаберендәге 13 нче номерлы редакциядә) Муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның

29 маендагы 77 нче номерлы карары белән расланган (2020 елның 18 нче декаберендәге 13 нче номерлы редакциядә) муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә, 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Песәй авыл җирлеге Советы Рәисе В.И. Мөхәммәтгалиев